ГЛАВА ШЕЛАНГОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Советская, д.7, с. Шеланга,
422577

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ШИЛАНГЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет ур., 7 нче йорт, Шилангы авылы,
422577

Тел.: (84379) 32-7-48, факс: (84379) 32-7-02.

08.11.2024 № 8

На № ______________ от ________________

Гражданнарның үзара салымын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең
Берек авылында гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлеге Уставы, 24 ст. нигезендә,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 28 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Берек авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«Югары Ослан муниципаль районының Шилангы авыл җирлегенең Берек авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 1850 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы?:
- Берек авылының торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын зиратка кадәр төзү, ремонтлау, карап тоту

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Йорт янындагы территориядә гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Берек авылы, Үзәк урамы, 17 йорт, 17:00 сәгатьтә.

4. Гражданнар җыенын оештыручы итеп Шилангы авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: В. В. Майоров